# Нәсыйхәт

Җомга
4
июль
2014
№28

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


Әңгәмә

# ТАТАР МИЛЛӘТЕНӘ СОКЛАНА



**Гыйсә мәдрәсәдә дәрес бирә. Габдрахман Хәбибуллин фотосы**

**Мамадышка икенче ел инде, Рамазан шәриф аенда Төркиядән коръән-хафиз, вәгазьче чакырылып, шәһәрдә үзенчәлекле азан авазы, Коръән аятьләре яңгырый. Узган ел ике төрек килгәннәр иде. Быел Гыйсә исемле кардәшебез бер ай буе булачак. Ул ТР мөселманнары Диния нәзарәте юлламасы белән Мамадышка тәравих намазлары үткәрү өчен килде. Мәхәлләә халкы очрашулар вакытында төрек кунагыбызга гаиләсе, Төркия Җөмһүрияте, Коръән ятлау серләре турында кызыксындырган сорауларын бирделәр. Гыйсә кардәшебез Мамадышта гына түгел, районның кайбер авыллары мәчетләрендә дә ифтар мәҗлесләрендә булып, бу авыллар халкына да үзенең моңлы тавышын ишеттерде – Коръән укыды. Рамазан ае дәвамында, чакыру буенча, ул башка авылларга да барырга ниятли.**

**Традициягә тугры калып, хөрмәтле кунак белән әңгәмә кордык.**

Ул сүзен Аллаһны мактау һәм пәйгамбәребезгә хәмед сәнәләр әйтеп башлады, Мамадыш мөхтәсибәтенә, мәдрәсә хезмәткәрләренә үзен олылап каршы алулары, кунак итүләре өчен рәхмәтен белдерде.

**–Төркиянең кайсы шәһәреннән сез? Үзегез белән якыннанрак таныштырсагыз иде?**

- Мин тумышым белән борынгы 5 миллион халкы булган Анкара шәһәреннән. Өйләнгәнмен, ике балам бар. 41 яшьтә.

**- Татарстанга килүегезнең максаты нәрсәдән гыйбарәт?**

– Мин намазларда Коръән укыйм, тәравих намазларын алып барам, дәресләр үткәрәм, менә мәдрәсәдә дә сәгать икедән алып дүрткә кадәр Коръән дәресләрен бирәм.

**– Кайларда белем алдыгыз?**

- Җиде яшьтән алып унике яшькә кадәр мәктәптә укыдым, унике яшьтән алып унтугыз яшькә кадәр имам-хатыйблар әзерли торган көллияттә белем алдым, унтугыз яшьтән алып егерме өч яшькә кадәр Анатолла университетының иләһият факультетында гыйлем өстәдем.

**- Хәзерге вакытта кайда эшлисез?**

- Биш ел Анкарадагы Сары Яр шәһәрендә Бараҗ мәчетендә имам-хатыйп булып эшләдем, хәзерге вакытта Кырык Калә шәһәрендә мәчеттә мөәзин вазыйфасын башкарам. Бу шәһәрдә 300 мең халык яши. Төп вазыйфам белән беррәттән мәчеттә дини белем дә бирәм.

**–Рамазан аенда коръән-хафиз буларак кайсы илләрдә булганыгыз бар?**

–Үткән елгы Рамазанны мин Мәккәдә идем. Быел монда үткәрергә насыйп булды.

**–Кайсы илдә изге айны үткәрү күңелегезгә хуш килде?**

–Әлбәттә инде Мәккә шәһәрендә. Андагы мохит аерата үзенчәлекле. Татарстанда да миңа ошый. Әмма сәхәр һәм ифтарга бик майлы итеп ашау әзерлиләр. Татарлар белән төрекләр ризыклары арасында аерма күп. Шуңа күрә әлеге ризыкларга ияләнеп булмый. Гомумән, алар күңелгә ятучан, бик тәмле.

**– Мамадышка карата фикерегез...**

– Казанга килеп төшкәч, мәркәзегез бик ыгы-зыгылы күренде, башкалагыз кайный. Биредә, Мамадышта мине җылы каршыладылар, яхшы кабул иттеләр, халык ачык. Мамадыш – гүзәл, тыныч, яшел шәһәр, яшәү өчен бик яхшы җир. Аның белән хәзрәтләр әкренләп таныштыра. Мин биредә үземне чит кеше кебек тә хис итмим.

**– Төркиядәге дини юнәлешләргә киңрәк тукталсагыз иде...**

- Төркиядә 85 процент халык традицион ислам юнәлешендәге Әбү-Хәнифә мәзһәбе буенча бара. Калганы – әлеге юнәлештә булган Шәфигый мәзһәбендә. Алар – икесе дә дөрес мәзһәб. Татарстанда иң мөһим бер момент бар: ул мөселманнар белән мөселман булмаганнарның тату мөгамәләдә яшәүләре. Бу исә башка илләр өчен дә үрнәк булып тора. Ата-бабалардан калган йолаларны тиешле үтәп баручы, дин үсешендә зур роль уйнаучы татар милләтенә сокланам. Төркиядә мәчетләр зуррак итеп төзелә.

**(Дәвамы 3нче биттә).**

Мөхәррир сүзе

# АЙЛАР СОЛТАНЫ– РАМАЗАН!

**Аллаһ Раббыбызга сансыз мактау вә хәмдесәнәләребез булсын. Рәсүлебез с.г.в.нең рух шәрифенә дип әйткән салават шәрифләребез булса иде һәм дә иң беренче Адәм г.с.нән алып бүгенге көнгә хәтле килеп киткән барлык мөэмин вә мөэминәләрнең дә рух шәрифләренә кылган догаларыбыз барып ирешсә иде.**

Хөрмәтле райондашлар, мөселман кардәшләр! Мамадыш мәдрәсәсе коллективы һәм газетабызның редакциясе исеменнән сезне вә бөтен мөселман кардәшләребезне 2014нче елның Рамазан ае белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез. Уникe айның солтаны булган Рамазан-Шәриф аена ирештереп, гөнаһлардан пакъланырга, Үзенең ризалыгын казанып хәерле-изге гамәлләр кылып, күп савапларга ирешергә Аллаһыбыз тагын бер мөмкинлек бирде. Без Рамазан аен сагынып көтеп алдык, Рамазан ае да күрәсең безне сагынып көткән, чөнки быел ул безгә ун көнгә иртәрәк килде.

Аллаһы Тәгалә һәрбер гыйбадәтне адәм баласы өчен үз хикмәте илә, һәм зур максат илә йөкләгән. Ураза тотуның хикмәте һәм максаты – тәкъвалыкны арттыру, ягъни Аллаһыга якынаю, аңа карата итагатебезне һәм буйсынуыбызны арттыру. Ураза гыйбадәте, һәрбер гамәл кебек фәкать Аллаһы ризалыгы өчен генә кылынырга тиеш. Берәр матди файда өчен тотылган уразаны Аллаһы кабул итмәс. Һичшиксез, Ураза тоту белән кеше Аллаһы Тәгалә каршында үзенең никадәр зәгыйфь һәм мохтаҗ булуын таный. Шуның белән аның горурлыгы, тәкәбберлеге киселә. Сусау, ачлык авырлыгын татып, фәкыйрь-мескеннәрне искә төшерә. Нәтиҗәдә, күңелендә аларга карата шәфкать, мәрхәмәт хисе уяна. Ураза тоту мөселманнарның ихтыяр көчен ныгыта. Тормыштагы авыр сынаулар алдында үзенә күрә бер әзерлек булып тора. Ураза тотучы кеше Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрнең кадерен белә башлый. Чөнки күп очракта булган нәрсә кадерләнми, югалгач кына кадере, кыйммәте беленә. Ләкин, шуны онытмаска кирәк - бозык, ялган сүзләр сөйләп, явызлыклар кылып йөрүчеләрнең ач торуларында күп хикмәт табылмас.

**«Әгәр бер кеше ялган сөйләүдән һәм ялган белән гамәл кылудан туктамаса, Аллаһы Тәгалә каршында аның ашамый, эчми торуында файда юк».** «Ураза Минем өчен генә тотыла, шуңа күрә аңа (хисапсыз) әҗерне Үзем белеп бирәм». Хәдис кудси.

Шиксез, Раббысының кушканына буйсынып, хәләл нәрсәләрдән баш тарткан кешенең, хәрам нәрсәләрдән баш тартмавы мөмкин түгел. Үзенең ихтыяр көчен ураза тотарга буйсындырган кеше башка сынаулар алдында да бирешмәс. Аллаһ Раббыбыз кешеләрне, рух һәм тән берлеге буларак, җир йөзендә яратты. Шуңа күрә тәнне дә, рухыбызны да тәрбияләү - безнең бурычыбыз. Тәнне мунча кереп чистартабыз, ә рухыбызны гыйбадәт кылып, гыйбадәтләрнең асылы булучы ураза тотып тәрбиялибез. Ураза тотуыбыз белән үзебезнең тән генә түгел, рух та икәнлегебезне искә төшерәбез, шулай итеп рухыбызны зурлыйбыз.

Газиз мөселман кардәшләр! Рамазан аен бер кунагыбызны каршылаган кебек каршыласак иде. Без берәр кунагыбызны каршылыйсы булсак, аңа алдан әзерләнә башлыйбыз, йортыбызда тәртип ясыйбыз, җыештырабыз. Шуның шикелле, Рамазан аена да алдан әзерләнергә тиешлебез. Гадәттә бәйрәмнәр күп булмый, әмма Рамазан ае безнең өчен бер айга сузылган зур бәйрәмдер. Чөнки бу мөбарәк айда Аллаһыга якынаябыз, гөнаһларыбыз кичерелә, ихласлыгыбыз арта. Болар барысы да безнең күңелләребезне шатлык белән тутыра. Рамазан ае безнең үзебезнең нәфесләребезгә бәя бирергә һәм үзебезне начар сыйфатлардан арындырырга мөмкинлек тудыра. Чөнки бу айда шайтаннар богауланган, димәк, барлык тискәре, начар сыйфатларыбыз күңелләребезнең бозык булуыннандыр. Шулай итеп күңелебезгә бәя биреп, начар гадәтләрне бетерергә тырышабыз. Шунысын да истә тоту тиешле, Рамазан аенда безнең барлык әгъзаларыбыз да ураза тотарга тиешле. Аларны гөнаһлы эшләрдән тыеп, изгелеккә юнәлттерү безнең бурычыбыздыр. Шулай ук, Рамазан ае ул ялкаулык ае да түгел. Киресенчә аерата активлык, хәрәкәт итү, үсеш ае булып тора. Чөнки тарихтан билгеле булганча нәкъ Рамазан аенда сәхәбәләр зур җиңүләргә ирешә торган булганнар. Бу айда Бәдр, фәтху әл-Мәккә кебек күренекле вакыйгалар булган. Кызганыч ки, безнең чорда күп кешеләрнең уразалары ифтар вакытларында карыннарын тутыру, көннәр буе йоклап ятудан гыйбарәт. Мондый уразаны Аллаһы Тәгалә кабул итәр микән соң?

Рамазан ае безгә яшәешебез нинди булырга тиеш икәнен дә күрсәтә. Безнең һәр көнебез Рамазан аендагы кебек гыйбадәттә һәм ихласлы итагатьтә үтәргә тиеш. Кызганыч ки, без күбебез Рамазан аенда ашкынып изгелекләр кылабыз, начар сыйфатлардан арынабыз, әмма Рамазан ае үтеп киткәч, яңадан сүлпәнлеккә биреләбез, гөнаһлы эшләргә кире кайтабыз. Мондый ураза нәтиҗәле булырмы? Чөнки уразабызның Аллаһы Тәгалә тарафыннан кабул булуы бер зур факторга бәйле. Әгәр дә Рамазан ае безне яхшы якка үзгәртми икән, Аллаһ белән элемтәбез яхшырмый икән, тәкъвалыгыбыз һәм ихласлыгыбыз артмый икән, димәк, бу уразаның Аллаһ тарафыннан кабул булуында шик бар.

Кайбер вакытта без Рамазан аенда фәлән эшләрне эшләрмен, фәлән гамәлләрне башкарырмын дип ният кылып йөрибез, әмма җитешә алмыйбыз, Рамазан үтеп китә. Болай булмасын өчен бу айга планны алдан төзеп кую хәерлерәк. Планыбызны төзегәндә Рамазан аеның өч үнкөнлеккә бүленгәнен истә тоту яхшы. Беренче дистәсе –рәхмәт, икечесе – гөнаһларны гафу кылу, өченчесе - уттан котылу үнкөнлеге. Димәк, әгәр дә куен дәфтәрендә бер айга исәпләнгән планыбыз булса, вакытыбызны тагын да рациональ куллана алачакбыз.

Рамазан ае - ул лидерлык мәктәбе дә. Бу айда без үзебезнең шәхсиятебезне тәрбия кылабыз, яңа үрләрне яуларга өйрәнәбез, яңа планнарны, яңа идеяларны гамәлгә ашырырга тырышабыз.

Рамазан ае безгә яшәешебезнең мәгънәсен искә төшерә. Без бит бу дөньяга гыйбадәт кылыр өчен яратылганбыз. Рамазан аенда бу хакыйкатьне без тагын да ныграк аңлый башлыйбыз, бары тик Аллаһ ризалыгы өчен генә яшәргә кирәклеген төшенәбез.

Быелгы уразабыз үзебезне исәпләргә яңа мөмкинлек тудыра. Ике рамазан арасында без нинди булдык, нәрсәләргә ирешә алдык? Без бүген үзебезгә ошбу сорауларны бирергә тиеш. Рамазан ае безнең егәрлегебезнең һәм потенциалыбызның индикаторы да булып тора. Бу айда булдыра алдык исә, димәк, башка айларда да булдыра алабыз дигән нәтиҗә ясарга этәрә.

Рамазан ае – ул авыр тормыш юлыбыздагы ял тукталышы кебек. 11 ай буе без арабыз, талчыгабыз, күп кенә гөнаһларыбыз җыела, рухи бушлык кичерә башлыйбыз. Шул мәлдә тормыш юлыбызда Рамазан дигән ял тукталышы пәйда була. Без бер ай буе ошбу тукталышта туктап үзебезгә калган унбер айга рухи ризык туплыйбыз, гәүдәләребезне, тәннәребезне авырайтып тора торган гөнаһлардан чистарынабыз, шулай итеп үзебезгә аккумулятор заряд алган кебек энергия һәм көч туплыйбыз. Рамазан аенда без үзебезгә “перезагрузка” ясыйбыз.

# АЙЛАР СОЛТАНЫ– РАМАЗАН!

Көнкүрешебездән беләбез, компьютерга “перезагрузка” ясасаң, ул күпкә тизрәк һәм яхшырак эшли башлый. Без дә - нәкъ шулай. Чөнки бу процесс вакытында без тискәре сыйфатлардан, гөнаһлардан, организмның төрле шлакларыннан арынабыз. Моннан соң безгә рәхәт һәм җиңел булып китә.

Әлбәттә, ураза тоту көннәре озыная, әмма моның белән, һичшиксез, аның әҗере дә арта. Әгәр әби-бабаларыбызны искә төшерсәк, зур гыйбрәтләр алырбыз. Алар басуларда, кырларда, ындыр табакларында эшләгәннәр, шул ук вакытта уразаларын да калдырмаганнар. Аллаһка шушылай итагатьле булганга күрә, әби-бабаларыбыз заманында хәзергедәй бозыклыклар да, тәртипсезлекләр дә булмаган.

Уйлап карасаң, бүген безнең яшәеш күпкә җиңелрәк: табында ни теләсәң, шул бар, алдынгы техника чаралары кулланып яшибез. Шуңа күрә зарлану урынсыздыр. Кызганыч ки, бүген күпләребез уразаның авырлыгына зарлана, эшенә сылтый, тагын әллә нинди сәбәпләр китереп чыгара. Кайберләребез, ураза тотырга мөмкинлеге була торып ятим-мескеннәргә, мәчет-мәдрәсәләргә акча биреп кенә котылмакчы. Әмма шуны онытырга ярамый – чын мәгънәсендә ураза тотырга сәламәтлеге һәм мөмкинлеге булмаган кеше генә мохтаҗларга акча биреп уразасын фидия кыла ала. Бу уңайдан, ураза тоту бик авыр дип әйтүчеләргә шуны исләренә төшерү кирәктер: җәннәт тә бит бик кыйммәтле, бәһале, тырышмыйча гына, берникадәр мәшәкатьләрне күрмичә генә аңа лаек булып булмый.

**Газиз кардәшләрем! Рамазан ае - безнең өчен тормыш мәдрәсәседер**. Рамазан-шәриф аенда Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам Аллаһы тарафыннан җибәрелгән Җәбраил фәрештәдән Коръән-Кәрим дәресләрен ала иде. Шуңа күрә бу айда без аерата күбрәк гыйлем алырга омтылыйк. Пәйгамбәребезнең иң бөек могҗизасы булган Коръән-Кәрим бу айда иңдерелгәне өчен, Рамазанда изге китабыбызны уку һә аны укып чыгу яки хәтем кылу зур әҗерле гамәлләрдән санала. Шуңа күрә Коръән-Кәримне укырга тырышыйк, гарәпчә укый алмасак, аңлатмаларын укып җаныбызга шифа алыйк.

Бу айда без фәкыйрьләрнең, ачларның хәлләрен аңлау дәресен үтәбез. Аларга карата күнелләребез йомшара. Гомумән, җир шарында бар халыкның биштән бере фәкыйрьлек хәлендә яшәгән вакытта, мөселман кешесенең күнеле тыныч булырмы? Шуңа күрә бу айда күбрәк мохтаҗларга булышыйк, ярдәм итик. Бу ай - мөселманнар арасында ярдәмләшү һәм ризыкның бәрәкәтле вә мул булган аедыр. Кем бу айда бер уразалы кешене ифтар кылдырса, гөнаһларының гафу ителүенә сәбәп булыр. Шуңа күрә мохтаҗларны, ураза тотучыларны ифтар кылдырырга тырышыйк. Бу айда без сабырлык дәресләрен дә алабыз. Күпләребез көн буе төрле гөнаһлар кылмыйча түзәргә өйрәнә, берәүләребез үзләрен гайбәттән тыеп тору дәрәҗәсенә ирешә. Бу зур дәрес түгелме? Һәрнәрсәнең ачкычы булган кебек, җиңүнең дә ачкычы - сабырлык. Без үзебезнең нәфесебезне җиңәргә тырышабыз. Ә нәфесне фәкать сабырлык белән генә җиңеп була. Аллаһы Тәгалә бу айда хәтта безне хәләл җефетләребездән дә арындырып торып, нәфесебезне кулга алырга өйрәтә.

**Пәйгамбәребез әйтте: «Ураза тотучы кеше начар сүзләр әйтмәсен һәм кычкырышмасын. Әгәр берәү аны мыскыл итеп сүксә, яки әйткәләшергә сәбәп эзләсә: «Мин ураза!» – дип әйтсен».**

Димәк, акыллы, игътибарлы мөселман бу мөбарәк Рамазан аеның һәрбер мизгелен игелек белән үткәрергә тырыша.

Хөрмәтле мөселманнар! Әйе, түземсезлек белән көтеп алынган Рамазан ае җир шарыбыз буйлап атлый. Бу вакыйга бер яктан, күңелгә шатлык, икенче яктан, җаваплылык өсти. Шатлык, чөнки Аллаһының рәхмәтенә якынаябыз, җаваплылык, чөнки, билгеле булганча, һәр башланган әйбернең ахыры бар, димәк, безгә күп кенә бүләкләр белән килгән кадерле кунагыбызны озатыр вакытлар да көттермәс. Шуңа күрә үкенечкә калмасын өчен Рамазан ае биргән бик күп кыйммәтле дәресләрне тормышыбызга ашырсак иде. Шушы дәвердә нәфесебезне җиңәргә, күңелне пакъләргә, хайван сыйфатларын җиңәргә өйрәнсәк иде. Әйе, бу айда без бихисап зур дәресләр алабыз. Аларны гомеребез буе үтәргә тырышсак иде. Чөнки калган 11 ай да - Аллаһныкы. Ул айларда да гөнаһ кылырга рөхсәт юк. Ураза тоту Рамазан белән генә чикләнми, безнең башка айларда да күп нәфел уразаларыбыз бар. Шәүвәл аенда 6 көн, һәр айның уртасында 3 көн, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә һәм гашура уразалары, калган айларда да Коръән-Кәрим уку, һәр ай саен бер хәтем кылу рәсүлебезнең сөннәтеннәндер. Калган айларда да фәкыйрьләрнең ризыкка мохтаҗ булуларын онытмасак иде.

Рамазан ае безгә юмартлык дәресләрен дә бирмичә калмас. Шунлыктан Раббыбызның ачуын китерә торган саранлыгыбыздан арынсак иде.

Хөрмәтле кардәшләр! Раббыбыз тоткан уразаларыбызны, кылган изгелекләребезне кабул итсен! Киләчәк Рамазан аен да исәнлектә каршы алып, уразаларны тотарга насыйп итсен! Раббыбыз, тормышларыбызның һәр көнен Рамазан шәриф аендагы кебек бәхетле, чиста һәм ихласлы, ә төннәребезне Кадер кичәләре кебек зекер һәм истигъфарлы итеп үткәрергә насыйп әйләсен.

Раббыбыз барча галәмгә муллык вә сәгадәт насыйп әйләсен!

Уникe айның солтаны булган Рамазан-Шәриф аена ирешеп гөнаһлардан пакъланырга, Үзенең ризалыгын казанып, хәерле-изге гамәлләр кылып, күп савапларга ирешергә тагын бер мөмкинлек бирде.

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**

# Татар милләтенә соклана

**(Ахыры. Башы 1нче биттә)**

Халык акчасына төзелгән дин йортларын дәүләт тота, имамнарга да хезмәт хакы түлиләр. Сезнең акчага күчереп исәпләгәндә имамнар 40 мең сум хезмәт хакы ала. Төркиядә дә ифтар мәҗлесләре үткәрәләр, тик алар мәчетләрдә түгел, ә мәчет янында, чатыр астында көйләнә. Мәчеткә җыелган сәдака акчалары мохтаҗларга бирелә. .

**–Коръәнне махсус алымнар белән өйрәтәсезме?**

–Әлбәттә, төрле алымнар бар. Мин күбрәк кабатлатыру ысулын кулланам. Башта берничә мәртәбә үзем укыйм, аннан соң укучылар минем арттан кабатлап баралар. Әмма, Коръән ятлаганда, ятладың да, калдырдың түгел, ә һәрдаим кабатлап тору ләзем.

**- Коръән ятлаучыларга нинди теләкләр һәм киңәшләр әйтер идегез?**

- Аллаһы Тәгалә бөтен кешегә дә Коръәнне аңларга һәм аны өйрәнергә мөмкинчелек бирми. Хафиз булу өчен бик күп имтиханнарны үтәргә кирәк. Шул сынауларны үтсәң генә Аллаһ сиңа Коръәнне бирә. Гөнаһ гамәлләр күбрәк кылган саен, Коръән истә калмый. Пәйгамбәребезнең сөннәтен яхшылап үтәү тормышта зур урын алып торырга тиеш. Никадәр сөннәт гамәлләрне күбрәк үтисең, шулкадәр хәтерләү сәләте яхшыра. Ә кирәкмәгән сүзләр сөйләү, гамәлләр кылу хәтерне начарайта. Шуңа күрә Коръәнне ятлау да авырлаша. Коръәнне ятлауда ният зур урын уйный. Әгәр дә кеше авырлыклар белән укый икән, укуын дәвам итсен. Чөнки аңа хафизлардан да күбрәк савап язылачак, иншә Аллаһ. Шундый хәдис бар: **“Коръәннән бер генә хәрефе дә булмаган кеше җимерелгән өйгә тиң.” Мамадышта да Коръән-хафизлар булдырырга кирәк.**

**- Әңгәмәгез өчен рәхмәт, сезгә уңышлар телибез!**

## Комганыма мәдхия

Иртән торып,
бисмилла әйтеп,
Ябам башыма яулык.
Дөнья куып, дин тотмадык,
Шуңа без надан калдык.
Иртән торып,
бисмилла әйтеп,
Кулыма алам комган.
Гыйбадәткә соңга калмыйк,
Килде бит шундый заман.
Комганыма сулар салам,
Саф чишмә суларыннан.
Намаз укып, зекер кылам,
Сихәт алам шулардан.
Дөньякүләм җәмгыятькә,
Аллаһым бир иминлек.
Барыбызга да, дин тотарга,
Күктән инде мөмкинлек.
Ният кылам, чистарынам,
Укыйм әвәл – Иманны.
Төзек иман, тугры юллар,
Чорнап алсын җиһанны.
Әй комганым, комганым,
Онытылдың күп дәвер.
Динебезнең, үзебезнең,
Патшасы булдың хәзер.
Алам кулыма комган,
Китәм гамәл юлына.
Ахирәт рәхмәтен сал,
Мин сөекле колыңа?!!

## “Апый” чишмәсе

Иң әвәле тау битләрен,
Сапый бабай таптаган.
Таптануы бушка китми,
Безгә кәүсәр калдырган.
Челтер-челтер
кыйбла юллап,
Ага “Апый” чишмәсе.
Яңы ямьле, суы тәмле,
Килми аннан китәсе.
Чишмә буе әрәмәлек,
Җәен сайрый сандугач.
Сагынамын саф чишмәмне,
Яшьлегем шунда узгач.
Тәмле суын эчеп үстек,
Уйнап тау буйларында.
Тәнгә-сихәт, җанга-рәхәт,
Тау чишмә суларында.
Челтер-челтер саф сулары,
Агып төшә инешкә.
Инешендә коеныл үстек,
Шул чагым һаман истә.
“Апый” суы кәүсәргә тиң,
Килә кәүсәр тәмнәре.
Әгәр сырхау әчә калса,
Сихәтләнә тәннәре.
Яшь киленнәр суга килә,
Ялтырый чиләкләре.
Хезмәт дәрте белән яна,
Ялкынлы йөрәкләре.
“Апый” чишмәсе дисәк тә,
Чын исеме Сафыйулла.
Сафыйулла онытылды,
Калды ул “Апый” гына.
Челтер-челтер
чишмәбезгә,
Читтән балчык ишмәгез.
Суын эчеп, монда яшик,
Чит җирләргә китмәгез.

**РАУЗА ХӨСНУЛЛИНА.**
**Түбән Сон авылы**

## Дөнья яңалыклары

### РИИДА 120 ШӘКЕРТКӘ ДИПЛОМ ТАПШЫРЫЛДЫ



Россия ислам институтында чыгарылыш тантанасы үткәрелде. Теология, лингвистика, ислам икътисады, шәригать фәннәре юнәлешендә гыйлем туплаган 120 шәкерткә диплом тапшырылды. Уку йортында үткәрелгән диплом тапшыру тантанасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, институт ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, Татарстан Президентының Дини оешмалар белән эшләү идарәсе җитәкчесе Илнур Гатауллин, уку йорты мөгаллимнәре, шәкертләр катнашты.

**Чыганак: Диния нәзарәте матбугат хезмәте**

### БАРАК ОБАМА ИФТАР МӘҖЛЕСЕ ОЕШТЫРАЧАК

Президент Барак Обама АКШ мөселманнарына кеше хокукларын яклау һәм илнең үсешенә керткән өлеше өчен рәхмәт белдерде.
АКШ Президенты Барак Обама быел да Ак Йортка ифтар мәҗлесенә АКШ үсешенә зур өлеш керткән танылган кешеләрне, мөселман дәүләтләре илчеләрен чакырачак. Аның көне соңрак хәбәр ителәчәк.
Обама һәр елдагыча үзе һәм тормыш иптәше Мишель ханым исеменнән АКШ һәм дөнья мөселманнарын Рамазан ае башлану уңаеннан котлады, -дип хәбәр итте **«Азатлык. орг».**

## Укырга чакырабыз

# Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

**Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе 2014-2015нче уку елына шәкертләр туплый.**
Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган.
**Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы 8/28, Телефоннар: 3-19-17, 89172802391**



## Белдерүләр

*1нче сентябрьдән мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.
*Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли.( Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)
*Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мөрәсимнәрне үткәрү. Мамадыш мәдрәсәсе, Муса Җәлил ур 8/28), тел: 89172802391
*1нче сентябрьдән Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз. Белешмәләр өчен телефон: 31917; 89172802391
*Мамадыш мәдрәсәсе яшь балаларны һәр ял көнендә уза торган укуларга чакыра. Укулар 1нче сентябрьдән һәр атнаның 9:00-11:00 сәгатьләрдә дәвам итәчәк. Яшь категориясе чикләнмәгән. Барлык укырга теләүчеләрне мәдрәсәбездә көтәбез.
*Мамадыш мәдрәсәсе читтән торып уку бүлегенә укучылар җыя. Укулар елга ике мәртәбә (1-10 гыйнвар һәм 20-30 апрель) оештырыла. Шәкертләр 10 көн дәверендә мәдрәсәдә белем алачаклар. Торак һәм ашау-эчү каралган. Белешмәләр өчен телефон: 31917; 89172802391 **Безнең адрес: М. Җәлил ур. 8/28 эл. Почта: mamadysh-medrese@mail.ru**

## МӨРӘҖӘГАТЬ

Мөхтәрәм райондашлар! Мөселман кардәшләр! Рамазан ае безгә юмартлык дәресләрен дә бирмичә калмас. Шунлыктан Раббыбызның ачуын китерә торган саранлыгыбыздан арынсак иде. Бүгенге көндә мәдрәсә яңа уку елына әзерләнә, бинага ремонт кирәк. Ел дәверенә шәкертләрне ризык белән тәэмин итү, укытучыларга хезмәт хаклары түләү өчен финанс булдыру - бик авыр эш. Һәм бу эштә бергә һәм бердәм булсак кына гамәлләребез нәтиҗәле булыр. Мәчет-мәдрәсәләребезне ятим итмик, маллабызны кызганмыйк, көчебездән килгәнчә гошер һәм фитраларыбыз белән ярдәм итик.

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 400 данә.**